ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

1 июль, 2024 ел № 34/10

Шәһәр Советының 2011 елның 25 августындагы 13/11 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

««Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»» 2024 елның 6 апрелендәге 76-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2011 елның 25 августындагы 13/11 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезләмәгә (Шәһәр Советының 2015 елның 27 февралендәге 38/8, 2015 елның 9 ноябрендәге 3/5, 2017 елның 24 октябрендәге 20/6, 2018 елның 10 августындагы 26/10, 2018 елның 8 ноябрендәге 27/12, 2019 елның 23 маендагы 31/8, 2020 елның 18 мартындагы 38/6, 2021 елның 4 августындагы 8/10, 2022 елның 2 ноябрендәге 17/10, 2023 елның 5 маендагы 23/10, 2023 елның 25 октябрендәге 27/11 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 21 пунктның 8 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә: «8) муниципаль милекне минималь рөхсәт ителгән бәя буенча сату;»;

2) 24 пунктның 3 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә: «3) башлангыч бәя (муниципаль милекне минималь рөхсәт ителгән бәя буенча сату очракларыннан тыш);»;

3) 29 пунктның 13 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«13) җиңүчеләрне (аукцион үткәргәндә, махсуслаштырылган аукцион, конкурс үткәргәндә), яисә сатып алучыларны (муниципаль милекне минималь рөхсәт ителгән бәя буенча сатканда), яисә муниципаль милекне сатып алу хокукына ия булган затларны (аны җәмәгать тәкъдиме аша сатканда) билгеләү тәртибе;»;

4) 34 пунктның 6 пунктчасын «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясындагы 4 пунктының икенче абзацында билгеләнгән очракта, минималь рөхсәт ителгән бәя буенча муниципаль милекне сатуда бердәнбер катнашучы дип танылган затлар» сүзләрен өстәргә;

5) 64 пунктта «бәясен игълан итмичә» сүзләрен «минималь рөхсәт ителгән бәя буенча» сүзләренә алыштырырга.

2. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ